ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«17» ноябрь2020 ел № 120-р

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының вакантлы вазыйфасы биләүгә
конкурс игълан итү турында

Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 14 декабрендәге 31-2 номерлы карары белән расланган Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының спорт һәм туризм бүлеге башлыгы - вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс игълан итәргә.

2. Конкурска документларны 2020 елның 20 ноябреннән сәгать 8дән 2020 елның 09 декабренең 16 сәгатенә кадәр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы хакимияте бинасында (Әгерҗе шәһәре, Гагарин урамы, 13 нче йорт, 2 нче кабинет) шимбә һәм якшәмбедән кала һәр көнне 8дән 16 сәгатькә кадәр кабул итәргә, тел. 2-31-00;

3. 7 кеше составында конкурс комиссиясен расларга (1-нче кушымта).

4. Конкурс комиссиясенең 2020 елның 11 декабрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм бүлеге башлыгы вазыйфасын биләүгә кандидатларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрергә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенә «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасында һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында конкурс турында игълан урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
17.11. 2020 № 120-р
күрсәтмәсенә 1 нче кушымта

**Конкурс комиссиясе составы**

1. Гыйльметдинова Р.Р. – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенен беренче урынбасары, комиссия рәисе;

**2.** Закирова Р.А. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары;

**Комиссия әгъзалары**:

1. Хәкимова Н.М. - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар бүлеге башлыгы, комиссия секретаре;
2. Фәтхетдинова Л.Г. - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы;
3. Иманова Л.С.- Әгерҗе муниципаль районынын коррупциягә каршы көрәш башлыгы ярдәмчесе (килештерү буенча);
4. Мурзин С.Е. – Әгерҗе районында Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе (килештерү буенча);
5. Абзалиева Д.З. - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы каршындагы дини һәм иҗтимагый оешмалар Советы әгъзасы, «Татмедиа» ААҖ филиалы «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы редакциясе мөхәррире (килештерү буенча)